| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>РУССКО-АЗЕЛЕЕВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>РУС ӘҖИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

---

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**2024 елның 26 ноябре** | Рус Әҗиле<br>ав. | **КАРАР**<br>**№ 22** |

Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлеге Башкарма комитетының Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 01 сентябрендәге 19 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Рус Әҗиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең баш администраторларының бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында.

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.1 статьясы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР ИТӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлеге Башкарма комитетының Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 01 сентябрендәге 19 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Рус Әҗиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәре баш администраторларының бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 пунктның «б» пунктчасының алтынчы абзацында «тапшыру» сүзеннән соң «түләнергә тиешле сумманы исәпләү гамәлгә ашырылган көннән дә соңга калмыйча»сүзләрен өстәргә.

1.2. 5 пунктның «б» пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү;

бюджетка түләүләр, алар буенча пенялар һәм штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруның Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләр нигезендә эшләнгән регламентын билгеләү;

Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм аның нигезендә кабул ителә торган бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган муниципаль хокукый актларда билгеләнгән башка бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр порталының Интернет челтәрендә

(http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Рус Әҗиле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Рус Әҗиле авылы, Центральная урамы, 1йорт (җирлек администрациясе бинасы), Карәшәм авылы, Новая урамы, 27 йорт (мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Рус Әҗиле авыл җирлеге башлыгы** **Г.Ф.Семахина**